
Бvгенге кондә китапны яратырга, теләп укырга чакыру максатын тормышка ашыручылар арасында моһим рольне Рузаевка районы Татар Пешлә авылы “БИТ-21” китапханәсе уйный. Китап укучыны һәм аз укучыны тагы да кvбрәк кызыксындыру очен гаилә белән бергә укыйбыз, Сергей Есенин поэзиясе һәм башка кvпторле чаралар vткәрәләр. Шулай чираттагы «Татар поэзиясе: йорәкне дулкынландырган сvз» дигән шигъри кичә Татар Пешлә авылы халкы очен vткән.      Әлеге чара 27 октябрь конне «Халык жырларынын беркайчан да тоныкланмый торган, чиста һәм vтә кvренмәле козгесе булуын истә тотарга кирәк» дигән Габдулла Тукай сvзләре эпиграфы астында укучылары очен торле буын татар шагыйрьләре ижат иткән матурлык һәм зирәклек доньясына чуму момкинлеге була. Беренче чиратта Мордовиябез жирендә туып vскән классик язучыларыбыз – Шәриф Камал, Хади Такташ, Абдрахман Абсалямов һәм башка язучыларыбыз турында сvз барды. Олкән буын халкы якташлары турында һәм аларнын ижатларын яратып укыйлар. Шәриф Камал турындагы яна материаллар аларны нык кызыксындыра. Хади Такташыбызнын поэзиясе кvнел тvрләрендә. Рузаевка районы Татар Пешлә “Бит-21” модель китапханәсе житәкчесе Леана Наиль кызы Чавкина, әйдәп баручы белгеч Ләйлә Рафаиль кызы Саляева торле чара vткәргәндә белемнәрен, жаннарынын бер олешен шул материалга куеп укучыларына  житкерергә тырышалар.

Кичәдә Ватанга мәхәббәт, туган табигатьнен матурлыгы, мәнгелек кыйммәтләр, кешелек тормышынын шатлыклары һәм кайгылары турында шигырьләр янгыраган. Чарада яратып катнашучы Венера Фатих кызы Багапова, Наилә Нияс кызы Мурсякаева, Халидә Хабибулла кызы Чермантеева, балалар - Амелина Зубрилкина, Аделина Курмаева, Аделина Мухаева, Элина Авязова, Эмиль Гараев һәм башкалар милли мәдәниятқә әверелгән классик әсәрләр белән ләззәтләнә алганнар. Китап яратучыларнын шигъри сvз белән ләззәтләнv генә тvгел, vз тәэсирләре белән уртаклашу, фикердәшләре белән аралашу һәм татар әдәбиятынын яна якларын ачу момкинлеге дә булган.

**Наилә НАСЫРОВА**